МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

25.08.2022 №269

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Б о е р ы к б и р ә м:

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртү муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында» 2016 елның 26 февралендәге 74 номерлы боерыгына (Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2018 елның 19 ноябрендәге 578 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен раслау турында»

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законны һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны

оештыруның аерым мәсьәләләре турында» федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын үтәү максатларында боерык бирәм:»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.»;

3 пунктта «А.В.Сидорова» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге боерык белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә даими рәвештә пассажирлар йөртүнең муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибендә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрын алып бару тәртибе»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның муниципальара маршрутлары реестрын алып баруның әлеге тәртибе (алга таба – Тәртип, Реестр, муниципальара маршрут, даими рәвештә пассажирлар йөртү) пассажирларны даими йөртә торган муниципальара маршрутлар турындагы белешмәләрне кертү, даими рәвештә пассажирлар йөртә торган муниципаль маршрут буенча гамәлгә ашырыла торган даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турындагы белешмәләрне кертү, муниципальара маршрутлар турындагы үзгәрешләрне кертү, муниципаль маршрутлар турындагы белешмәләрне Реестрдан төшереп калдыру кагыйдәләрен раслый.»;

түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пункт өстәргә:

«Әлеге Тәртип максатлары өчен «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы федераль законда кулланыла торган төп төшенчәләр кулланыла;

6 пунктның унынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«даими рәвештә пассажирлар йөртә торган муниципальара маршрутны билгеләү яки үзгәртү турындагы карарда, дәүләт контрактында һәм (яки) даими рәвештә пассажирлар йөртә торган муниципальара маршрут буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелә торган ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга гаризада каралган транспорт чараларының сыйфатламалары (транспорт чараларының төрләре, транспорт чараларының класслары, транспорт чараларының экологик сыйфатламалары, транспорт чараларыннан файдалануның максималь чоры, транспорт чараларының пассажирлар йөртү сыйфатына йогынты ясый торган

сыйфатламалары);»;

7 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бирелә торган юридик зат, шәхси эшкуар, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучылар турындагы белешмәләр Реестрга мондый таныклыклар һәм карталар бирелгән көннән соңгы икенче көннән дә соңга калмыйча кертелә.»;

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турында карар кабул ителүе турындагы белешмәләр Реестрга мондый карар кабул ителгән көннән башлап 5 эш көне эчендә кертелә.

Даими рәвештә пассажирлар йөртә торган муниципальара маршрут буенча җайга салынмый торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турындагы белешмәләр Реестрга даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турындагы карар үз көченә кергән көннән башлап 5 эш көне эчендә яки муниципальара маршрут буенча даими рәвештә пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык һәм тиешле маршрут карталары ачык конкурс үткәрмичә генә бирелә торган юридик зат, шәхси эшкуар яки гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы вәкаләтле зат белән килештерелгән башка чор дәвамында кертелә.

Даими рәвештә пассажирлар йөртә торган муниципальара маршрут буенча җайга салына торган тарифлар буенча даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турындагы белешмәләр Реестрга даими рәвештә пассажирлар йөртү төрен үзгәртү турындагы карар үз көченә кергән көннән башлап 5 эш көне эчендә кертелә.».

Министр Ф.М.Хәнифов

Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл
хуҗалыгы
министрлыгының 2016
елның 11 апрелендәге
133 номерлы боерыгы
белән расланды
(Татарстан Республикасы
Транспорт һәм юл
хуҗалыгы
министрлыгының
_______________________
№______ боерыгы
редакциясендә)

Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның төбәкара маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы тукталыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителә торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлеге

| т/с | Муниципаль берәмлек атамасы | Торак пунктының исеме | Тукталыш пункты исеме | Тукталыш пункты урнашкан урын |
|---|---|---|---|---|
| 1. Әлмәт | | | | |
| 1.1. | Әлмәт | Әлмәт ш. | Әлмәт шәһәре автовокзалы | ТР, Әлмәт шәһәре, Герцен урамы, 1 А |
| 2. Арча | | | | |
| 2.1. | Арча | Арча ш. | Арча шәһәре тукталыш пункты | ТР, Арча шәһәре, Коммуна урамы, 6 |
| 3. Азнакай | | | | |
| 3.1. | Азнакай | Азнакай шәһәре | Азнакай шәһәре автовокзалы | ТР, Азнакай шәһәре, Гагарин урамы, 18 |
| 4. Әгерҗе | | | | |
| 4.1. | Әгерҗе | Әгерҗе шәһәре | Әгерҗе шәһәре тимер юл | ТР, Әгерҗе шәһәре, Вокзал урамы, 17 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | | вокзалында тукталыш пункты | |
| 5. Бөгелмә | | | | |
| 5.1. | Бөгелмә | Бөгелмә шәһәре | Бөгелмә шәһәре автовокзалы | ТР, Бөгелмә шәһәре, Ягъфәров урамы, 18 |
| 6. Буа | | | | |
| 6.1. | Буа | Буа ш. | Буа тимер юл вокзалы ст. тукталыш пункты | ТР, Буа шәһәре, Тимер юл урамы, 79 |
| 6.2. | | Вольнистан авылы | Вольнистан авылы тукталыш пункты | ТР, Вольнистан авылы, Калинин урамы |
| 7. Баулы | | | | |
| 7.1. | Баулы | Баулы шәһәре | Баулы шәһәре автовокзалы | ТР, Баулы шәһәре, С.Сәйдәшев урамы, 1Б |
| 8. Чүпрәле | | | | |
| 8.1. | Чүпрәле | Иске Чүпрәле авылы | Иске Чүпрәле авылы автостанциясе | ТР, Иске Чүпрәле, Техническая урамы, 3 |
| 8.2. | | Иске Шатрашан авылы | Иске Шатрашан авылы тукталыш пункты | ТР, «Иске Чүпрәле – Татар Шатрашаны» 23+900 |
| 8.3. | | Мочәли авылы | Мочәли авылы тукталыш пункты | ТР, «Матак – Мочәли» 1+990 |
| 8.4. | | Зур Өтәк авылы | Зур Өтәк авылы тукталыш пункты | ТР, «Иске Чүпрәле - Татар Шатрашаны» 7+270 |
| 8.5. | | Иске Шәйморза | Иске Шәйморза авылы | ТР, «Казан - Ульяновск» - Иске |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | авылы | тукталыш пункты | Чүпрәле» 13+000 |
| 9. Алабуга | | | | |
| 9.1. | Алабуга | Алабуга ш. | Алабуга шәһәре автостанциясе | ТР, Алабуга шәһәре, Чапаев урамы, 76 йорт, А/2 |
| 10. Зеленодольск | | | | |
| 10.1. | Зеленодольск | Зеленодольск ш. | «Мирный» автовокзалы | ТР, Зеленодольск шәһәре, Королев урамы, 1А |
| 11. Казан | | | | |
| 11.1. | Казан | Казан шәһәре | «Столичный» автовокзалы | ТР, Казан шәһәре, Девятаев урамы, 15 |
| 11.2. | | Казан шәһәре | «Южный» административ-эшчәнлек үзәге» тукталыш пункты | ТР, Казан шәһәре, Оренбург юлы, 207 |
| 11.3. | | Казан шәһәре | «Восстание» тимер юл вокзалындагы тукталыш пункты | ТР, Казан шәһәре, Воровский урамы, 33 |
| 11.4. | | Казан шәһәре | «Восточный» автостанциясе | ТР, Казан шәһәре, Аграр урамы, 8 |
| 12. Кайбыч | | | | |
| 12.1. | Кайбыч | Олы Кайбыч ш.т.п. | Олы Кайбыч ш.т.п. автостанциясе | ТР, Олы Кайбыч ш.т.п., Р.Гарафетдинов урамы, 1В |
| 12.2. | | Мәлки авылы | Мәлки авылы тукталыш пункты | ТР, Мәлки авылы, Гагарин урамы,4 |
| 13. Лениногорск | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13.1. | Лениногорск | Лениногорск шәһәре | Лениногорск шәһәре автостанциясе | ТР, Лениногорск шәһәре, Вахитов урамы, 10 йорт, 1 корылма |
| 14. Мамадыш | | | | |
| 14.1. | Мамадыш | Мамадыш шәһәре | Мамадыш шәһәре автостанциясе | ТР, Мамадыш шәһәре, Давыдов урамы, 150а |
| 15. Минзәлә | | | | |
| 15.1. | Минзәлә | Минзәлә шәһәре, | Минзәлә шәһәре автостанциясе | ТР, Минзәлә шәһәре, Чаллы тракты урамы, 32 |
| 16. Чаллы | | | | |
| 16.1. | Чаллы | Чаллы шәһәре | Чаллы шәһәре тимер юл вокзалында тукталыш пункты | ТР, Чаллы шәһәре, М.Җәлил проспекты, 7 |
| 17. Түбән Кама | | | | |
| 17.1. | Түбән Кама | Түбән Кама шәһәре | Түбән Кама шәһәре автовокзалы | ТР, Түбән Кама шәһәре, Вокзал урамы, 7 |
| 18. Яңа Чишмә | | | | |
| 18.1. | Яңа Чишмә | Яңа Чишмә авылы | Яңа Чишмә авылы автостанциясе | ТР, Яңа Чишмә авылы, Ленин урамы, 33а |
| 19. Нурлат | | | | |
| 19.1. | Нурлат | Нурлат шәһәре | Нурлат шәһәре автовокзалы | ТР, Нурлат шәһәре, Гыйматдинов урамы, 62 йорт, 2Н бина |
| 20. Сарман | | | | |
| 20.1. | Сарман | Сарман авылы | Сарман авылы тукталыш пункты | ТР, Сарман авылы, Ленин урамы, 35 |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 20.2. | | Җәлил ш.т.п. | Җәлил ш.т.п. тукталыш пункты | ТР, Җәлил ш.т.п., Әхмәдиев урамы, 10 |
| 21. Тәтеш | | | | |
| 21.1. | Тәтеш | Тәтеш шәһәре | Тәтеш шәһәре тукталыш пункты | ТР, Тәтеш шәһәре, Тәтешкә 200 ел урамы, 1 А |
| 21.2. | | Тәтеш шәһәре | Тәтеш шәһәре тукталыш пункты | ТР, Тәтеш шәһәре, Тәтешкә 200 ел урамы, 1 Б |
| 22. Тукай | | | | |
| 22.1. | Тукай | «Бегишево» аэропорты | «Бегишево» аэропорты тукталыш пункты | ТР, Биклән авылы, «Бегишево» аэропорты |
| 23. Чистай | | | | |
| 23.1. | Чистай | Чистай шәһәре | Чистай шәһәре тукталыш пункты | Чистай шәһәре, К.Маркс урамы, 125 |
| 24. Чирмешән | | | | |
| 24.1. | Чирмешән | Чирмешән авылы | Чирмешән авылы тукталыш пункты | ТР, Чирмешән авылы, Техническая урамы, 38 |
| 25. Ютазы | | | | |
| 25.1. | Ютазы | Урыссу ш.т.п. | Урыссу ш.т.п. автовокзалы | ТР, Урыссу ш.т.п., Козин урамы, 38 |
| Татарстан Республикасында автомобиль транспортында һәм җир өсте шәһәр электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж алып баруның төбәкара маршрутлары буенча башлангыч һәм (яки) ахыргы туктатыш пунктлары сыйфатында файдаланырга рөхсәт ителә торган, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан тукталыш пунктлары исемлегенә җәмгысе 36 туктатыш пункты кертелгән | | | | |